**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3173**
**20.06.2019**

Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылыкны
яклаучы изге Петр һәм Феврония
Муромскийларны искә алу көнен
оештыру һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2018 елның 1 ноябрендәге 6510 нчы карары белән расланган «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы халыкларының милләтара элемтәләрен һәм дуслыгын ныгыту һәм шәһәр халкының ялын оештыру максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәдәният идарәсенә 2019 елның 8 июлендә «Боровецкий» бульварында, Яр Чаллы шәһәренең «Орган залы» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесендә Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылыкны яклаучы изге Петр һәм Феврония Муромскийларны искә алу көнен үткәрергә.

2. Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылыкны яклаучы изге Петр һәм Феврония Муромскийларны искә алу көненә әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын 1 нче кушымтада каралганча расларга.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылыкны яклаучы изге Петр һәм Феврония Муромскийларны искә алу көнен оештыру һәм үткәрү буенча чыгымнарны финанслауга акча бүлеп бирүне 2019 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәдәният» 0801 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 30 000 (утыз мең) сум күләмендә, 2 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенә (Н.Д. Закировка) «Боровецкий» бульварында чара үткәрү урынында гражданнар иминлеген һәм җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

5. Башкарма комитетның түбәндәге карарларын гамәлдән чыгарырга:

1) «Яр Чаллы шәһәрендә Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көнен бәйрәм итүгә багышланган чара үткәрү турында» 2019 елның 14 июнендәге 3033 нче карарын;

2) «Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылыкны яклаучы изге Петр һәм Феврония Муромскийларны искә алу көнен оештыру һәм үткәрү турында» 2019 елның 14 июнендәге 3043 нче карарын.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 20 июнендәге
3173 нче карарына
1 нче кушымта

Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылыкны яклаучы изге Петр һәм Феврония Муромскийларны искә алу көненә әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Хәлимов Рамил Мәрван улы | оештыру комитеты рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 2. | Әхмәтова Гөлнар Карл кызы | Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе |
| 3. | Галимов Искәндәр Нургаләм улы | Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте башлыгы |
| 4. | Галиуллин Рөстәм Рәфыйк улы | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенең җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге башлыгы |
| 5. | Желавская Оксана Александровна | Башкарма комитетның оештыру бүлеге башлыгы |
| 6. | Закиров Надир Дамир улы | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе башлыгы (килешенү буенча) |
| 7. | Зарипова Равилә Гыйльметдин кызы | «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы |
| 8. | Ишалина Ландыш Риф кызы | Яр Чаллы шәһәренең «Чишмә» халыклар дуслыгы йорты» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе директоры |
| 9. | Кәрамиев Румил Рәүф улы | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы |
| 10. | Кислов Александр Иванович | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте башлыгы |
| 11. | Мөхәммәтҗанова Римма Равил кызы | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе башлыгы |
| 12. | Решетняк Лидия Евгеньевна | Яр Чаллы шәһәренең «Орган залы» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе директоры |
| 13. | Сафиуллин Рим Миннур улы | Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе директоры |
| 14. | Солтанова Рәисә Кәүсәр кызы | Башкарма комитет икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенең кулланучылар базары бүлеге башлыгы |
| 15. | Харисов Винер Хәмит улы | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы. |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 20 июнендәге
3173 нче карарына
2 нче кушымта

Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылыкны яклаучы
изге Петр һәм Феврония Муромскийларны искә алу көнен үткәрү буенча чыгымнар
сметасы

| Т/с | Чыгымнарның исеме | Сумма (сум) | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Сәхнә бизәү | 7 800,00 | «Орган залы» МАМУ |
| 2. | Полиграфия хезмәтләре:<br>- чакыру открыткалары әзерләү | 7 200,00 | |
| 3. | Бүләкләнүче гаиләләргә чәчәк букетлары | 15 000,00 | |
| | барлыгы: | 30 000,00 | |

Барысы: 30 000 (утыз мең) сум 00 (ноль) тиен.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова